**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**«Созвездие-Йолдызлык» республика фестиваль хәрәкәтенә ярдәм итү буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы совет составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Созвездие-Йолдызлык» республика фестиваль хәрәкәтенә ярдәм итү буенча чаралар турында» 2006 елның 29 апрелендәге ПУ-165 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2007 елның 16 июлендәге ПУ-357 номерлы, 2007 елның 17 декабрендәге ПУ-686 номерлы, 2009 елның 17 апрелендәге ПУ-208 номерлы, 2012 елның 20 августындагы ПУ-682 номерлы, 2012 елның 7 декабрендәге ПУ-1043 номерлы, 2015 елның 17 мартындагы ПУ-290 номерлы, 2015 елның 16 октябрендәге ПУ-992 номерлы, 2017 елның 16 июнендәге ПУ-508 номерлы, 2018 елның 14 мартындагы ПУ-231 номерлы, 2018 елның 14 маендагы ПУ-369 номерлы һәм 2019 елның 27 августындагы ПУ-499 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган «Созвездие-Йолдызлык» республика фестиваль хәрәкәтенә ярдәм итү буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы совет составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Совет составыннан Р.И. Вәлиевны, Р.А. Ратникованы, А.А. Фоминны чыгарырга;

б) Совет составына кертергә:

Вәлиева Зилә Рәхимҗан кызын – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисен (килешү буенча);

Сәлимгәрәев Айдар Сәетгәрәй улын – Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесен;

в) Совет әгъзаларының вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Ә.С. Гобәйдуллинның – «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе, Совет рәисе урынбасары (килешү буенча)»;

А.Р. Зариповның – «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 06 март
№ ПУ-154